РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» декабрь 2025г. г. Альметьевск № 15

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.11.2025, 994 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018, 182 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә сайлаулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәткә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 113 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 58 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 67 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 82 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 92 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 145 номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге 161 номерлы, 2025 елның 7 маендагы 173 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

(сумнарда)

| «Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 46 383 |

| | |
|---|---|
| Идарә җитәкчесе, мөстәкыйль бүлек җитәкчесе (мөдире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 32 164 |
| Идарә җитәкчесе урынбасары, мөстәкыйль бүлек җитәкчесе (мөдире) урынбасары, башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 26 916 |
| Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 26 916 |
| Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек җитәкчесе | 26 916 |
| Сектор мөдире | 25 223 |
| Баш белгеч | 24 715 |
| Әйдәп баручы белгеч | 23 192 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 21 499» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны, финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 январеннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Бочкарев Н.А.).

Шәһәр Башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Г.М. Хәбутдинова